ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

03 03 2020 г. № 59

Гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү турында

«Социаль наем шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган һәм салым салынырга тиешле керемнең әлеге законга кушымтада бәян ителгән иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы нигезендә, карар бирәм:

1. Гражданнарны азкеремлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондында социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләре билгеләргә:

1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.1.1. Ялгыз кеше өчен – 28 951,20 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 18 423,50 сум;

1.1.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 15 791,50 сум.

1.2. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче кеше өчен – 1 354 221,0 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 1 723 554,0 сум;

1.2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 2 215 998,0 сум;

1.2.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 2 954 664,0 сум;

1.2.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 3 693 330,0 сум.

2. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2019 елның 25 февралендәге 35 номерлы «Гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге башлыгы Е.С. Митрошенковага йөкләргә.

Җитәкче ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН Д.И. Баландин